**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«30» 09 2024 ел №4029

16:39:072201 кадастр кварталында Түбән Суыксу авылы территориясе өлешен планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү буенча документацияне эшли башлау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 15 январендагы 41 номерлы карары белән расланган 16:39:072201 кадастр кварталында Түбән Суыксу авылы территориясенең бер өлешен планлаштыру һәм ызанлау проектына 16:39:072201:1128 кадастр номерлы җир кишәрлеген күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонага кертү өлешендә үзгәрешләр кертү буенча документацияне эшли башларга.
2. Проектлаштыруны территориаль планлаштыру документлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, техник регламентлар таләпләре нигезендә алып барырга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин